ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 3 пунктының беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), № 11 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Җәмәгать судьясының вәкаләтләре туктатылганда яисә туктатып торылганда, шулай ук җәмәгать судьясы вакытлыча урынында булмаган (авыру, чираттагы ял һәм башка нигезле сәбәпләр) башка очракларда аның вазыйфаларын башкару тиешле район суды рәисе карары белән шул ук суд районының башка суд участогы җәмәгать судьясына йөкләнә. Әгәр суд районында күрсәтелгән нигезләр буенча урынында булмаган җәмәгать судьясы вазыйфаларын шул ук суд районының башка җәмәгать судьясына йөкләү мөмкин булмаса (суд районында җәмәгать судьясы урыны бары бер генә булса яисә суд районының башка җәмәгать судьялары вакытлыча урыннарында булмаса), аның вазыйфаларын башкару югарыдагы суд рәисе яисә аның урынбасары карары белән үз эшчәнлеген иң якындагы суд районында башкаручы җәмәгать судьясына йөкләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 71-ТРЗ